2023 елның 6 ноябре № 14

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 6 ноябрендә «Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 360 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? - Шилангы авылының Завод урамында урамнарны яктыртуны ремонтлау, дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 29 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 18 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 18 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә халык җыены булды, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. “Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә 2024 елда Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 360 сум күләмендә үзара салым кертүгә, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы гражданнардан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллау белән килешәсезме? - Шилангы авылының Завод урамында урамнарны яктыртуны ремонтлау, дигән сорау буенча карарны кабул итәргә.

3. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В.В.Майоров